**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**АЛЬКЕЕВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
422870, С.Базарные Матаки,
ул.С.Крайнова, д.56

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘЛКИ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422870, ТР Базарлы Матак авылы,
С.Крайнов ур.,56

Телефон: (84346) 20-0-26, факс: (84346) 21-7-60. E-mail: alkay@tatar.ru, сайт: www.alkeevskiy.tatarstan.ru.

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 елның «17» ноября 462 №

**«Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Вәзгыять үзәген төзү һәм Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Вәзгыять үзәге турында нигезләмәне раслау хакында»**

Татарстан Республикасында бүленгән ситуацион үзәкләр челтәрен булдыру чараларын гамәлгә ашыру максатларында, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Вәзгыять үзәген булдырырга.

2. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Вәзгыять үзәге турында кушымтада бирелгән Нигезләмәне расларга.

3. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Вәзгыять үзәген булдыру һәм аның эшчәнлеге өчен җаваплылык үзәге дип Вәзгыять үзәк администраторы вәкаләтләре белән тәэмин итеп, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеген билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең территориаль үсеш буенча урынбасарына ике атна эчендә, йөкләнгән өстәмә функцияләрне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертергә,

шулай ук Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Вәзгыять үзәге администрациясе өчен җаваплы вазыйфаи затны билгеләргә.

5. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының җирле үзидарә органнарына Вәзгыять үзәктә эшләгәндә әлеге карарга нигезләнеп эш итәргә тәкъдим итәргә.

6. Таблица нигезендә мәгълүмати-аналитик модельләрне җаваплылык үзәге буларак бүлекчәләргә беркетергә:

| Мәгълүмати-аналитик модель исеме | Бүлекчә исеме (җаваплылык үзәге) |
|---|---|
| Кече бизнес секторының тулай территориаль продуктка йогынтысын бәяләү | Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге муниципаль район баланс комиссиясе белән берлектә |
| Хезмәт хакын МХХК (МРОТ) кадәр җиткерүнең бюджетка керүгә йогынтысын бәяләү | Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы (килешү буенча) |
| Кече бизнесның хуҗалык итүче субъектларына чагыштырма анализ | Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге |
| Җирле бюджетка ФЗКС (НДФЛ) күчерү нормативын фаразлау | Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Финанс – бюджет палатасы (килешү буенча) |

7. Җаваплы структур бүлекчәләргә модельләрне актуальләштерү чоры нигезендә, мәгълүмати-аналитик модельләрне паспортларында күрсәтелгән актуаль халәттә саклауны тәэмин итәргә.

8. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең территориаль үсеш буенча урынбасарына функциональ бүлекчәләр җитәкчеләре белән берлектә бер ай эчендә:

мәгълүмати ресурслар һәм мәгълүмати-аналитик модельләр паспортын эшләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты

билгеләгән тәртиптә аларны Чикле вәзгыять үзәгенең мәгълүмат ресурслары һәм мәгълүмат-аналитика модельләре реестрына кертергә;

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Вәзгыять үзәгендә мәгълүмат ресурсларын һәм мәгълүмат-аналитик модельләрне формалаштыру һәм актуальләштерү регламентын, шулай ук аларны өстәү, корректировкалау һәм кулланыла торган объектлар исемлегеннән төшереп калдыру тәртибен эшләргә һәм Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә раслауга кертергә;

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Вәзгыять үзәге мәгълүматларының электрон базасына эштә кулланыла торган мәгълүмати ресурсларны кертергә һәм аларны актуальләштерүне, мәгълүмати-аналитик модельләр эшләү өчен кирәкле чыгыш күрсәткечләрен актуальләштерүне тәэмин итәргә;

мәгълүматлар базасын һәм модельләрне администрацияләү өчен җаваплы хезмәткәрләрне беркетергә.

9. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

10. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Әлки муниципаль районы**
**Башкарма комитет җитәкчесе:** **И.В. Юсупов**

Расланган
Татарстан Республикасы
Әлки муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның «17» ноябре
402 № карары

# Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Вәзгыять үзәге турында Нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Вәзгыять үзәгенең (алга таба - ӘМР ВҮ) бурычларын, функцияләрен һәм эшчәнлек тәртибен билгели.

1.2. Әлеге Нигезләмәдә кулланыла торган терминнар :

мәгълүмати ресурс – мәгълүмат системаларында мәгълүмат, документлар, документ массивлары;

мәгълүмати-аналитик модель – башлангыч мәгълүмат нигезендә идарә итү күрсәткечләрен анализлау һәм формалаштыру алгоритмы;

мәгълүмат системасы – мәгълүмат җыелмасы һәм аны эшкәртүне тәэмин итүче мәгълүмат технологияләре;

мәгълүмат ресурслары реестры-вәзгыять үзәгендә катнашучылар эшчәнлегендә кулланыла торган мәгълүмат ресурсларын һәм аларны тәшкил итүчеләрне исәпкә алу максатларында билгеләнгән тәртиптә төзелүче мәгълүмат ресурслары исемлеге;

мәгълүмати-аналитик модельләр реестры- үз эшчәнлегендә вәзгыять үзәгендә катнашучылар тарафыннан файдаланыла торган, башлангыч мәгълүмат нигезендә билгеләнгән тәртиптә төзелә торган анализ алгоритмнары һәм идарә итү күрсәткечләре исемлеге;

вәзгыять үзәге администраторы- вәзгыять үзәге эшчәнлеген тәэмин итүче Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге;

Татарстан Республикасының бүленгән вәзгыять үзәге (алга таба – БВҮ) - бердәм регламентлар (мәгълүмати һәм административ) буенча үзара хезмәттәшлек итүче функциональ бәйсез, әмма мәгълүмати яктан бәйле мәгълүмат ресурслары һәм вәзгыять үзәкләренең мәгълүмати-аналитик модельләре җыелмасы;

вәзгыять үзәген кулланучылар- үз эшчәнлегендә мәгълүмат ресурслары һәм вәзгыять үзәк кысаларында башкарыла торган модельләштерү нәтиҗәләрен кулланучы Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы җирле үзидарә органнарының функциональ бүлекчәләре.

1.3. ӘМР ВҮ Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының җирле үзидарә органнары җитәкчеләре өчен идарә итү карарлары һәм

мәгълүмат-аналитик материаллар проектларын әзерләүне тәэмин итүгә билгеләнгән мәгълүмат ресурсларының, мәгълүмат-аналитик модельләрнең, мәгълүмат системаларының һәм мәгълүматны эшкәртүнең һәм чагылдыруның программа-техник чараларының оештыру-технологик комплексыннан гыйбарәт

1.4. ӘМР ВҮ БВҮнең состав элементы булып тора.

## 2. Вәзгыять үзәге бурычлары

ӘМР ВҮ бурычлары булып тора:

2.1. Идарә итү карарлары һәм мәгълүмати-аналитик материаллар проектларын әзерләү өчен файдаланыла торган мәгълүмат-аналитик модельләр эшләү өчен кирәкле мәгълүматны җыюны, эшкәртүне һәм анализлауны тәэмин итү.

2.2. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы җирле үзидарә органнарының оператив һәм стратегик характердагы килештерелгән карарларына мәгълүмати-аналитик ярдәм күрсәтүне тәэмин итү.

2.3. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башлыгы, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, аның профильле бүлекчәләре, шулай ук дәүләт һәм муниципаль хакимият органнары, Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты аппаратлары, мөрәҗәгатьләре буенча мәгълүмат, мәгълүмати-белешмә һәм мәгълүмати-аналитик материаллар әзерләү.

2.4. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы тормыш-көнкүрешенең теге яки бу өлкәләрендә вәзгыяти һәм/яки имитацион үсешен модельләштерүне гамәлгә ашыру.

2.5. ӘМР ВҮдә эшкәртелә торган мәгълүматны саклау дәрәҗәсен тәэмин итү.

## 3. Вәзгыять үзәгендә катнашучыларның хокуклары

3.1. ӘМР ВҮ администраторы хокуклы:

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы җирле үзидарә органнарының функциональ бүлекчәләреннән билгеләнгән тәртиптә ӘМР ВҮ эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле мәгълүматны соратып алырга;

үз компетенциясенә керә торган мәсьәләләр буенча билгеләнгән тәртиптә ӘМР ВҮ дәүләт хакимияте органнарында, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының җирле үзидарә органнарында, башка учреждениеләрдә һәм оешмаларда тәкъдим итәргә.

3.2. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының җирле үзидарә органнары җитәкчеләре һәм аларның функциональ бүлекчәләре ӘМР ВҮ кулланучылары булып торалар.

ӘМР ВҮ кулланучылары хокуклы:

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башлыгы карары белән билгеләнә торган функциональ бурычларга һәм аларның статусына карап,тулы яисә чикләнгән күләмдә мәгълүмати ресурсларга, мәгълүмати-аналитик модельләргә һәм ӘМР ВҮ мәгълүмат системаларына кертелергә;

билгеләнгән тәртиптә ӘМР ВҮнең мәгълүмат-аналитик ресурсларыннан бер яки периодик рәвештә тематик җыелмалар алырга.

## 4. Вәзгыять үзәге эшен оештыру

4.1. ӘМР ВҮнең администраторы булып Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге тора.

4.2. Мәгълүматны саклау эше Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының мәгълүматлаштыру һәм җәмәгатьчелек белән элемтә бүлеге тарафыннан башкарыла.

4.3. ӘМР ВҮ администраторы контрольдә тота:

ӘМР ВҮнең хезмәт күрсәтүен;

ӘМР ВҮнең агымдагы эшчәнлеген һәм үсешен тәэмин итүне.

4.4. Кулланучыларның ӘМР ВҮ мәгълүмат ресурсларыннан файдалана алуы ӘМР ВҮ мәгълүмат куркынычсызлыгы сәясәте нигезендә, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе карары белән билгеләнә торган ӘМР ВҮ администраторы тарафыннан бирелә.

4.5. ӘМР ВҮ администраторы ӘМР ВҮ мәгълүмати ресурслар һәм мәгълүмати-аналитик модельләр реестрын үзәкләштереп алып бара.

## 5. Мәгълүмат иминлеген тәэмин итү

ӘМР ВҮ мәгълүмат ресурсларыннан файдаланучыларның файдалана алуын оештыру барлык юнәлешләр буенча мәгълүмат иминлеген тәэмин итү таләпләрен һәм принципларын исәпкә алып гамәлгә ашырыла:

мәгълүматны мәгълүмати-техник йогынтылардан (компьютер атакларыннан) яклау;

мәгълүматны рөхсәтсез керүдән саклау;

тиешле статуслы мәгълүмат ресурсларыннан чикләнгән файдалануны тәэмин итү;

мәгълүмати ресурсларның резерв күчермәләре.

Л. Р. Сәлахиева
21750